ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БЕГИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Клубная д. 1, с. Бегишево, Заинский район, 423511

Клубная урамы, 1нче йорт, Бигеш авылы, Зәй районы, 423511

Телефон, факс 3-82-25. Электронный адрес:Beg.zai@tatar.ru.сайт:http://zainsk.tatarstan.ru/rus/ begishevskoe.htm

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 7** **02 апрель 2025ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2018 елның 27 декабрендәге 160 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре турында " Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен, күрү сәләте буенча инвалидны озата йөрүче юл күрсәтүче эттән тыш, түбәндәге урыннарны билгеләргә:
- файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре
- халык күп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар, борындыкларда һәм

тезгеннәрдә аларның хуҗалары күзәтүе астында:
-Бигеш авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Ленин урамыннан 60 метр ераклыкта;
- Бигеш авылының төньяк өлешендә Гагарин урамыннан 60 метр ераклыкта;
- Керәкес авылының төньяк өлешендәҮзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
- Керәкес авылының көньяк өлешеннән Үзәк урамыннан 60 метр ераклыкта;
- Карман авылының төньяк өлешендәҮзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
- Карман авылының көньяк өлешендә Елга аръягы урамыннан 60 метр ераклыкта;
- Түбән Лождъы авылының көньяк өлешендә Үзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
- Түбән Лождъы авылының төньяк өлешендә Заречная урамыннан 60 метр ераклыкта; -
- Югары Лождъы авылының төньяк өлешендәҮзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
- Югары Лождъы авылының көньяк өлешендә Болотная урамыннан 60 метр ераклыкта;
-Югары Лождъы авылының көньяк-көнбатыш өлешендә Урман урамыннан 60 метр ераклыкта;
- Байрак авылының көньяк-көнбатыш өлешендәҮзәк урамнан 60 метр ераклыкта;
Әлеге пунктның тәэсире озата йөрүче юл күрсәтүче этләргә кагылмый.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3.Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында", бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Бигеш авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Р.Вәлиев.**